**ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ЗАКУПКАМ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ САТЫП АЛУЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

26.05.2023 № 09-07-04

Казан шәһәре

Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитетында норматив хокукый актларның һәм норматив хокукый акт проектларының ришвәтчелеккә каршы экспертизасы турында

2009 нчы елның 17 нче июлендә кабул ителгән 172-ФЗ номерлы «Норматив хокукый актларның һәм норматив хокукый акт проектларының ришвәтчелеккә каршы экспертизасы турында» Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 нчы елның 26 нчы февралендә чыгарылган 96 номерлы «Норматив хокукый актларның һәм норматив хокукый акт проектларының ришвәтчелеккә каршы экспертизасы турында» карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 нчы елның 24 декабрендә чыгарылган 883 номерлы «Кайбер норматив хокукый актларның һәм норматив хокукый акт проектларының ришвәтчелеккә каршы экспертизасын үткәрү Тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр керту турында» карары нигезендә б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитетында норматив хокукый актларның һәм норматив хокукый акт проектларының ришвәтчелеккә каршы экспертизасын үткәрү Тәртибен (кушымтада бирелә) расларга:

2. Түбәндәге боерыкларны гамәлдән чыккан дип танырга:

Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитетының 2016 нчы елның 12 нче апрелендә язылган 04-14-49 номерлы «Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитетында норматив хокукый актларның һәм норматив хокукый акт проектларының ришвәтчелеккә каршы экспертизасы турында» боерыгы;

Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитетының 2017 нче елның 24 нче мартында язылган 04-14-40 номерлы «Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитетының 2016 нчы елның 12

нче апрелендә язылган 04-14-49 номерлы «Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитетында норматив хокукый актларның һәм норматив хокукый акт проектларының ришвәтчелеккә каршы экспертизасы турында» боерыгына үзгәрешләр кертү турында» боерыгы;

Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитетының 2019 нчы елның 12 нче августында язылган 04-05-94 номерлы «Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитетының 2016 нчы елның 12 нче апрелендә язылган 04-14-49 номерлы «Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитетында норматив хокукый актларның һәм норматив хокукый акт проектларының ришвәтчелеккә каршы экспертизасы турында» боерыгына үзгәрешләр кертү турында» боерыгы;

Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитетының 2021 нче елның 5 нче августында язылган 04-05-94 номерлы «Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитетының 2016 нчы елның 12 нче апрелендә язылган 04-14-49 номерлы «Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитетында норматив хокукый актларның һәм норматив хокукый акт проектларының ришвәтчелеккә каршы экспертизасы турында» боерыгына үзгәрешләр кертү турында» боерыгы;

3. Әлеге боерыкның үтәлешен үзем контрольдә тотачакмын.

Рәис Р.Н.Сабиров

Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитетының 2023 нче елның 26 нчы маенда язылган 09-07-04 номерлы боерыгы белән расланган

Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитетында норматив хокукый актларның һәм норматив хокукый акт проектларының ришвәтчелеккә каршы экспертизасын үткәрү
Тәртибе

## 1. Гомуми кагыйдәләр

1.1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитетының (алга таба – Дәүләт комитеты) норматив хокукый актларының һәм норматив хокукый акт проектларының һәм шулай ук Дәүләт комитеты тарафыннан әзерләнә торган Татарстан Республикасының норматив хокукый акт проектларының (алга таба – актлар, акт проектлары) ришвәтчелеккә каршы экспертизасын үткәрү процедурасын билгели.

1.2. Ришвәтчелеккә каршы экспертиза «Норматив хокукый актларның һәм норматив хокукый акт проектларының ришвәтчелеккә каршы экспертизасын үткәрү турында» Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 нчы елның 24 нче декабрендә кабул ителгән 883 номерлы карары белән расланган «Аерым норматив хокукый актларның һәм норматив хокукый акт проектларының ришвәтчелеккә каршы экспертизасын үткәрү Тәртибе», әлеге Тәртип, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан 2010 нчы елның 26 нчы февралендә билгеләнгән «Норматив хокукый актларның һәм норматив хокукый акт проектларының ришвәтчелеккә каршы экспертизасын үткәрү турында» Методикасы (алга таба – Методика) буенча үткәрелә.

1.3. Ришвәтчелеккә каршы экспертиза өчен алынган актларны (акт проектларын) исәпкә алу әлеге Тәртипнең 2.1 нче пунктында күрсәтелгән кеше тарафыннан башкарыла.

1.4. Ришвәтчелеккә каршы экспертиза нәтиҗәләренә нигезләнеп, әлеге Тәртип Кушымтасында китерелгән форма буенча нәтиҗә ясала.

## 2. Дәүләт комитеты актларының ришвәтчелеккә каршы экспертизасы

2.1. Дәүләт комитеты актларының ришвәтчелеккә каршы экспертизасы Дәүләт комитетының дәүләт контрактларын үтәү бүлеге тарафыннан башкарыла. Норматив хокукый актларның һәм норматив хокукый акт проектларының ришвәтчелеккә каршы экспертизасын үткәрү өчен җаваплы булган Дәүләт комитетының дәүләт контрактларын үтәү бүлеге белгече (алга таба – җаваплы зат) Дәүләт комитеты рәисенең боерыгы белән билгеләнә.

2.2. Дәүләт комитеты актларының ришвәтчелеккә каршы экспертизасы чыгарыла торган норматив хокукый актларга һәм әзерләнә торган норматив

хокукый акт проектларына карата хокук куллануны мониторинглау кысаларында Методикага ярашлы рәвештә һәм Дәүләт комитеты рәисе боерыгы белән расланган тәртиптә үткәрелә.

Көчен югалткан яисә гамәлдән чыгарылган норматив хокукый актларга карата ришвәтчелеккә каршы  экспертиза үткәрелми.

2.3. Актның ришвәтчелеккә каршы экспертизасы җаваплы зат тарафыннан акт алынган көннән алып биш көн эчендә үткәрелә.

2.4. Ришвәтчелеккә каршы экспертиза нәтиҗәсе әлеге Тәртипнең 1.4 нче пункты нигезендә төзелгән бәяләмә белән рәсмиләштерелә.

Актның ришвәтчелеккә каршы экспертизасы нәтиҗәсе турында бәяләмә төзелгәннән һәм имзаланганнан соң бер эш көненнән дә соңга калмыйча актны ришвәтчелеккә каршы экспертизага җибәргән кешегә хәбәр ителә.

2.5. Актта ришвәтчелеккә бәйле факторларның булуы турында бәяләмә төзелгән һәм имзаланган көннән соң бер эш көненнән дә соңга калмыйча җаваплы зат тарафыннан Дәүләт комитеты рәисенә җибәрелә.

2.6. Бәяләмә нәтиҗәләре буенча актта ришвәтчелеккә бәйле факторлар ачыкланган очракта, Дәүләт комитеты рәисе аңа төзәтмәләр кертү яисә актны гамәлдән чыккан итеп тану турында карар кабул итә.

2.7. Шушы актны төзегән структура бүлекчәсе әлеге Тәртипнең 2.6 нчы пунктында күрсәтелгәнчә, Дәүләт комитеты рәисе карар кабул иткәннән алып өч көн эчендә  Дәүләт комитеты актына ярашлы проект әзерли һәм аны ришвәтчелеккә каршы экспертизага җаваплы затка юллый. Мондый проектның ришвәтчелеккә каршы экспертизасы әлеге Тәртипнең 3 нче бүлеге буенча үткәрелә.

## 3. Дәүләт комитеты акт проектларының, шулай ук Дәүләт комитеты тарафыннан әзерләнә торган Татарстан Республикасы акт проектларының ришвәтчелеккә каршы экспертизасы

3.1. Дәүләт комитеты акт проектларының, шулай ук Дәүләт комитеты тарафыннан әзерләнә торган Татарстан Республикасы акт проектларының ришвәтчелеккә каршы экспертизасы хокукый экспертиза үткәрелгән вакытта җаваплы зат тарафыннан башкарыла.

3.2. Акт проекты ришвәтчелеккә каршы экспертиза үткәрү өчен акт проектын эшләү өчен җаваплы булган Дәүләт комитетының структура бүлекчәсенең вазифаи заты тарафыннан җибәрелә.

3.3. Ришвәтчелеккә каршы экспертиза акт проекты алынган көннән алып биш көн эчендә җаваплы зат тарафыннан үткәрелә.

3.4. Акт проектында ришвәтчелек белән бәйле факторлар булган очракта ришвәтчелеккә каршы экспертиза нәтиҗәсе әлеге Тәртипнең 1.4 нче пункты буенча төзелгән бәяләмә белән рәсмиләштерелә.

Ришвәтчелеккә каршы экспертиза бәяләмәсе  төзелгән көнендә акт проектын юллаган Дәүләт комитетының структура бүлекчәсенә бирелә.

3.5. Акт проектын төзегән Дәүләт комитетының структура бүлекчәсе, ришвәтчелек белән бәйле факторлар булган очракта, бәяләмә алынган көннән

башлап 3 көн эчендә акт проектын тулыландыра һәм аны икенче катка ришвәтчелеккә каршы экспертиза үткәрү өчен җаваплы затка юллый.

3.6. Икенче катка ришвәтчелеккә каршы экспертиза, әлеге Тәртипнең 3.4 нче һәм 3.5 нче пуктларында билгеләнгән рәвештә, тулыландырылган акт проекты алынган көннән башлап өч көн эчендә үткәрелә.

## 4. Дәүләт комитеты актларының һәм акт проектларының ришвәтчелеккә каршы бәйсез экспертизасы

4.1. Ришвәтчелеккә каршы бәйсез экспертиза объектлары булып Дәүләт комитеты әзерләгән, рәсми рәвештә басылып чыккан һәм Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең Интернет мәгълүмат-коммуникация челтәрендәге рәсми порталына (http://goszakupki.tatarstan.ru/ (алга таба – рәсми сайт) яисә ришвәтчелеккә каршы бәйсез экспертиза үткәрү һәм җәмәгать белән фикер алышу максатында Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының норматив хокукый акт проектларын урнаштыру өчен бердәм төбәк интернет порталы буларак билгеләнгән мәгълүмат ресурсында (http://tatarstan.ru/regulation) урнаштырылган норматив хокукый акт проектлары санала.

Дәүләт серен яисә конфиденциаль характердагы мәгълүматларны үз эченә алган норматив хокукый актларга һәм акт проектларына карата ришвәтчелеккә каршы бәйсез экспертиза үткәрелми.

4.2. Дәүләт комитеты тарафыннан әзерләнүче Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы тәртибендә Россия Федерациясе Федераль Җыены Дәүләт Думасына кертеләчәк федераль закон проектларының, Татарстан Республикасы Рәисенең указ проектларының, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларлары проектларының ришвәтчелеккә каршы бәйсез экспертизасын үткәрү өчен Дәүләт комитеты аларны, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең тиешле башкарма органнарына, башка органнарга һәм оешмаларга килешүгә юллаган көнгә туры китереп, Интернет мәгълүмат-коммуникация челтәрендәге үзенең рәсми сайтына һәм бердәм төбәк интернет-порталына урнаштыра.

Дәүләт комитеты эшләнә торган акт проектларының ришвәтчелеккә каршы бәйсез экспертизасын үткәрү өчен аларны Дәүләт комитетының дәүләт контрактларын үтәү бүлегенә карауга җибәрелгән көнгә туры килгән эш көне дәвамында Интернет мәгълүмат-коммуникация челтәрендәге үзенең рәсми сайтына һәм бердәм төбәк интернет-порталына урнаштыра.

4.3. Дәүләт комитетының норматив хокукый акт проектының ришвәтчелеккә каршы бәйсез эскпертизасын үткәрү өчен проектны эшләүче норматив хокукый акт проектын, эксперт бәяләмәләрен юллау өчен адресны (шулай ук электрон почта адресын), шулай ук ришвәтчелеккә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча бәяләмәләрне кабул итә башлау һәм тәмамлану көнен күрсәтеп, Дәүләт комитетының дәүләт контрактларын үтәү бүлегенә юллый. Сайтка урнаштырылачак норматив хокукый акт проектларының проектны эшләүче тарафыннан билгеләнгән

ришвәтчелеккә каршы бәйсез экспретизасын үткәрү вакыты урнаштырылган көннән алып кимендә 5 эш көнен тәшкил итә.

4.4. Дәүләт комитетының дәүләт контрактларын үтәү бүлегенең җаваплы заты норматив хокукый акт проектын хокукый идарә тарафыннан карауга юлланган көнгә туры килгән эш көне дәвамында Интернет мәгълүмат-коммуникация челтәрендәге рәсми сайтына һәм бердәм төбәк интернет-порталына урнаштыра.

4.5. Ришвәтчелеккә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча бәяләмәләр, әгәр дә алар норматив хокукый акт проекты ришвәтчелеккә каршы бәйсез экспертиза үткәрү максатларында сайтта урнаштырылган вакыт чикләрендә кабул ителсә, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының ведомствоара электрон документлар әйләнешенең бердәм системасында кабул ителгән көннең икенче көненнән дә соңга калмыйча теркәлә.

4.6. Ришвәтчелеккә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча бәяләмә рекомендация характерында бирелә. Ришвәтчелеккә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре нигезендә ясалган бәяләмә, әлеге Тәртипнең 4.7 нче пунктында күрсәтелгән очракларны исәпкә алмаганда, аны теркәгән көннән алып 15 көн эчендә Дәүләт комитеты тарафыннан мәҗбүри каралырга тиеш.

Карау нәтиҗәләре буенча ришвәтчелеккә каршы бәйсез экспертиза үткәргән физик яисә юридик затка нигезле җавап (йомгакта ришвәтчелеккә бәйле факторлар ачыклану яисә ачыкланган факторларны юкка чыгару турында мәгълүматлар булмаган очракларны исәпкә алмаганда) юллана. Анда ришвәтчелеккә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләрен исәпкә алу һәм (яисә) норматив хокукый актта яисә норматив хокукый акт проектында ачыкланган ришвәтчелеккә бәйле фактор белән килешмәүнең сәбәпләре чагыла.

4.7. Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый акт проектларына бәйсез экспертиза үткәрү буенча эксперт буларак Россия Федерациясе Юстиция министрлыгында  аккредитация узмаган юридик һәм физик затлар тарафыннан әзерләнгән;

Россия Федерациясе Юстиция министрлыгы раслаган формага туры килмәгән ришвәтчелеккә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча бәяләмәләр каралмый.

4.8. Әлеге Тәртипнең 4.7 нче пунктының өченче абзацында күрсәтелгән очракта Дәүләт комитеты андый бәяләмәне, сәбәпләрен күрсәтеп, теркәлгән көннән алып 15 көннән дә соңга калмыйча, кире кайтара.

4.9. Акт проектының ришвәтчелеккә каршы бәйсез экспертизасын үткәргән вакытта ришвәтчелеккә бәйле факторлар ачыкланса, алар шушы акт проектын эшләүче тарафыннан акт проектын камилләштерү стадиясендә бетерелә.

4.10. Ришвәтчелеккә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча бәяләмәдә бәян ителгән кимчелекләрне бетергәннән һәм тәкъдимнәрне исәпкә алганнан соң, проектны эшләүче, ришвәтчелеккә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча бәяләмәләр белән бергә, акт проектын, кабат тикшерү өчен, Дәүләт комитетының хокукый  идарәсенә тапшыра.

Кабат тикшерү җаваплы зат тарафыннан өч көн эчендә гамәлгә ашырыла.

4.11. Әгәр актта ришвәтчелеккә бәйле факторлар ачыкланса, Дәүләт комитетының бу актны әзерләгән структура бүлекчәсе, бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча бәяләмә Дәүләт комитетында теркәлгән көннән алып өч көн

эчендә актка үзгәрешләр кертү яисә актны көчен югалткан дип тану буенча чаралар күрә.

4.12. Ришвәтчелеккә каршы экспертиза нәтиҗәләре, шул исәптән бәйсез эскпертиза үткәрелеп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карар проектларында, Татарстан Республикасы Рәисе указларының проектларында, Татарстан Республикасының закон проектларында, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы тәртибендә Россия Федерациясе Федераль Җыены Дәүләт Думасына кертеләчәк федераль закон проектларында ришвәтчелеккә бәйле факторлар булуны дәлилләгән нәтиҗәләр белән килешмәгән очракта, актны әзерләүче, күрсәтелгән закон проектларын, ришвәтчелеккә каршы экспертиза, шул исәптән бәйсез экспертиза нәтиҗәсе белән килешмәвенең сәбәбе күрсәтелгән аңлатма язуы белән бергә Татарстан Республикасы Хөкүмәте, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән Регламент тәртибендә, карау өчен, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертә.

Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча Дәүләт комитетында норматив хокукый актларның һәм акт проектларының ришвәтчелеккә каршы экспертизасын үткәрү Тәртибенә Кушымта

Форма

Ришвәтчелеккә каршы экспертиза
бәяләмәсе

2003 нче елның 17 нче июлендә кабул ителгән 172-ФЗ номерлы «Норматив хокукый актларның һәм норматив хокукый акт проектларының ришвәтчелеккә каршы экспертизасы турында» Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 нчы елның 24 декабрендә чыгарылган 883 номерлы «Кайбер норматив хокукый актларның һәм норматив хокукый акт проектларының ришвәтчелеккә каршы экспертизасын үткәрү Тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр керту турында» карары белән расланган Кайбер норматив хокукый актларның һәм норматив хокукый акт проектларының ришвәтчелеккә каршы экспертизасын үткәрү Тәртибе, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 нчы елның 26 нчы февралендә чыгарылган 96 номерлы «Норматив хокукый актларның һәм норматив хокукый акт проектларының ришвәтчелеккә каршы экспертизасы турында» карары белән расланган Норматив хокукый актларның һәм норматив хокукый акт проектларының ришвәтчелеккә каршы экспертизасын үткәрү методикасы нигезендә Дәүләт комитетының дәүләт контрактларын үтәү бүлеге тарафыннан ришвәтчелеккә каршы экспертиза үткәрелде

______________________________________________________________________

(реквизитлар, норматив хокукый актның исеме /норматив хокукый акт проектының исеме)

1 нче вариант: Тәкъдим ителгән норматив хокукый актта ришвәтчелек белән бәйле факторлар ачыкланмады.

2 нче вариант: Тәкъдим ителгән норматив хокукый актта (норматив хокукый акт проектында) ришвәтчелек белән бәйле факторлар ачыкланды*.

Ачыкланган ришвәтчелек белән бәйле факторларны бетерү өчен түбәндәгеләр тәкъдим ителә

______________________________________________________________________

(ришвәтчелек белән бәйле факторларны бетерү ысулы күрсәтелә)

(ришвәтчелеккә каршы экспертиза үткәрү өчен җаваплы затның вазифасының исеме) (имза) (инициаллары, фамилия)

* Ришвәтчелек белән бәйле факторлар ачыкланган норматив хокукый актның (норматив хокукый акт проектының) нигезләмәләре чагыла, аның структур берәмлекләре (бүлекләр, маддәләр, өлешләр, пунктлар, пунктчалар, абзацлар) һәм ришвәтчелек белән бәйле факторлар күрсәтелә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 нчы елның 26 нчы февралендә чыгарылган 96 номерлы «Норматив хокукый актларның һәм норматив хокукый акт проектларының ришвәтчелеккә каршы экспертизасы турында»» карары белән расланган Норматив хокукый актларның һәм норматив хокукый акт проектларының ришвәтчелеккә каршы экспертизасын үткәрү методикасы нигезләмәләренә сылтама бирелә.